**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**заключительный этап**
**2023-2024 учебный год**
**10 класс**

**I. Бирелгән мәкальләрдә кайсы антоним парлар кулланыла? Тәкъдим ителгән вариантлардан сайлап алыгыз.** / Какие антонимические пары будут уместны в данных пословицах? Выберите из данных пар подходящие антонимы. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла).*

1. Күз – **куркак .**, кул – **батыр.**
2. Тәвәккәлгә **көн** дә бер, **төн** дә бер.
3. **Аяз** елны алма күп, **явым** елны гөмбә күп.
4. **Җиңел** эш – бармак башында, **авыр** эш – йөрәк башында.
5. **Зур** фил дә **кечкенә** тычканнан курка.

**II. 1) Табышмакның җавабын табыгыз; 2) җавап сүздәге хәрефләрдән исем сүз төркеменә караган яңа сүзләр төзеп языгыз. Бер хәреф бер генә тапкыр кулланыла ала. /** Найдите ответ загадки. Составьте новые слова-имена существительные из букв ответа загадки. Каждая буква может быть использована только 1 раз. *(10 баллов. За правильную отгадку – 5 баллов. Каждое слова оценивается по 1 баллу. Максимум – 5 баллов.).*

Юк аягы, юк күзе,
Сөйли, өйрәтә үзе.
Телгә аннан оста юк,
Аннан якын дус та юк.

***Җавап: китап***
***Яңа сүзләр:*** **тап, ит, кит, кап, ат**

**III.** *Көзге кебек идәндә ул яланаягыннан яфрак-яфрак дымлы эзләр калдырып, сине үзе белән ияртә дә хәзер кыя-таулар аша салам түбәле өйгә алып кайта* (М.Галиев). **Җөмләдән төрле ысуллар белән ясалган сүзләрне табып языгыз, ясалу ысулларын күрсәтегез. /** Найдите примеры из предложения на разные способы словообразования и укажите их. *(5 баллов. Каждый верный способ словообразования оценивается по 1 баллу.)*

**Җавап**: *морфологик* – дымлы, фонетик – хәзер; *синтаксик: кушма* – яланаяк, *парлы* – кыя-таулар, морфологик-синтаксик: *тезмә* – салам түбәле

**IV. Бирелгән сүзләр һәм аларда очрый торган грамматик категорияләр арасында тәңгәллекләр урнаштырыгыз. /** Установите соответствия между словами и их грамматическими категориями *(5 баллов. Каждое правильное соответствие оценивается по 1 баллу.)*

| | |
|---|---|
| 1. Авылга | А) дәрәҗә |
| 2. Кызым | Ә) заман |
| 3. Яшькелт | Б) килеш |
| 4. Барды | В) юнәлеш |
| 5. Сөйләш | Г) тартым |

**Җавап: 1 Б 2 Г 3 А 4 Ә 5 В**

**V. Русча фразеологизмнарның татарча эквивалентларын табыгыз. /** Напишите татарские эквиваленты, соответствующие выражениям на русском языке. *(15 баллов. За каждый правильный вариант по 3 балла.)*

**Махнуть рукой** – кул селтәү, өмет өзү
**Ломать голову** – баш вату
**Когда на горе рак свистнет** – кызыл кар яугач
**Как две капли воды** – ике тамчы су кебек, суйган да каплаган
**Была не была** – беткән баш беткән, аллага тапшырдым

**VI. Татар телендә аваз ияртемнәре турында ниләр беләсез? 1) Аваз ияртемнәренең төрләре; 2) дөрес язылышы, составлары ягыннан төрләре; 3) аларның сөйләмдә кулланылышы. Мисаллар белән аңлатыгыз. /** Что Вы знаете о звукоподражаниях в татарском языке? Объясните примерами: 1) виды звукоподражаний; 2) правописание, состав; 3) употребление их в речи. (15 баллов. Каждый пункт оценивается 5-ю баллами)

**Аваз ияртемнәре** – үзенчәлекле сүз төркеме. Кеше тавышына, хайван һәм кош-корт, бөҗәкләр чыгарган авазларга, һәм төрле җансыз предметлар тудырган авазларга охшатып ясалган сүзләр телнең сүзлек составында үзенчәлекле катламны тәшкил итә, һәм бу авазлар һәр телнең үз үзенчәлекләре нигезендә ясала. Мәсәлән, татар һәм рус телләрендә: *кикерикүк ~ кукареку, һау-һау ~ гав-гав, келт-келт ~ тик-тик* һ.б.

Тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре белән бергә, кеше яки предмет хәрәкәтен, яктылык яки башка билге буенча табигать күренешен “образлы итеп күз алдына китерү өчен” (Д. Г. Тумашева) дә төрле **ияртемнәр**

кулланыла. Аларны гадәттә “образ ияртемнәре” дип атыйлар: *ялт, гөлт, җем-җем, җәлт-җәлт* һ.б.

Тематик яктан телдәге аваз ияртемнәрен берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. ***Хайван, җәнлек, кош-корт, бөҗәк тавышларын тасвирлый торган аваз ияртемнәрею***. Татар телендә бу төркемгә кергән аваз ияртемнәре бай һәм күптөрле, һәм алар әдәби әсәрләр телендә дә шактый мул чагылыш таба.

*Йорт хайваннары* тавышының тасвиры: *иһа-һа-һай, бә-ә, һау-һау, эм-мә-ә, ләң-ләң, мики-ки, му-у* һ.б.

*Кош-корт* тавышларының тасвиры: *ка-ка-ка, кыйгак, кикрикүк, кыт-кыт-кыт, пи-би-би, бак-бак, гөлдер-гөлдер* һ.б.

*Ерткыч җәнлекләр* тавышыннан әдәби әсәрләрдә күбрәк бүре авазының тасвиры теркәлгән:

*Бөҗәкләр* тавышының тасвиры: *безз-безз* – черки тавышы, *чарр-чарр* – чикерткә тавышы һ.б.

***2. Җансыз предметлар чыгарган тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре.*** Мондый тасвирлар телдә шулай ук күптөрле: *чаж-пож, шарт-шорт, гөрс-гөрс, шыбыр-шыбыр, шатыр-шотыр, дырк-дырк, даң-доң, келт-келт, тырр-тырр, зырр-зырр, тик-так, гөбер-гөбер, шалт-шолт, тырр-пырр, кылтыр-кылтыр* һ.б.

***3. Кеше хәрәкәте тудырган тавышка охшатып ясалган аваз ияртемнәре:*** *дөп-дөп, лап-лап, шап-шап, шак-шык, лакыр-локыр, чап-чоп, тырт-тырт, тып-тып, тыз-быз, тыпыр-тыпыр, мештыр-мештер, мыштыр-мыштыр* һ.б.

4. ***Кеше тавышына охшатып ясалган аваз ияртемнәре***: *ха-ха-ха, хи-хи-хи, үә-үә, мышык-мышык, пыш-пыш, гөж-гөж, мыдыр-медер, эһем, корык-корык, лыш-лыш, чырык-чырык* һ.б.

**Образ ияртемнәре.**

*Яктылык һәм төс* тасвирлары: *ялт, гөлт, ялт-йолт, ялтыр-йолтыр, ялык-йолык, җем-җем һ.б.*

*Хәрәкәт тасвирлары*: *тыр-тыр, тыз-быз, җил-җил, кәз-кәз, фырт-фырт, мелт-мелт, дерт-дерт, челт-челт, дер-дер һ.б.*

*Эчке сиземләүгә, психик халәткә* бәйле тасвирлар: *жу, дер-дер, дерт, леп-леп, сулк-сулык һ.б.*

Аваз һәм образ ияртемнәре төзелеше буенча берничә төргә бүленә:

а) ялгызак ияртемнәр: *гөрс, гөлт, дык, лып, чалт, выжт, дерт, чулт һ.б.;*

б) парлы ияртемнәр: *ялт-йолт, лаштыр-лоштыр, шак-шок, шалтыр-шолтыр, калтыр-колтыр, чыш-пыш;*

в) кабатланып килгән иятремнәр: *дер-дер, мелт-мелт, кар-кар, кыйгак-кыйгак, тыпыр-тыпыр, кәз-кәз, җил-җил, дөбер-дөбер, шыгыр-шыгыр һ.б.;*

г) өч компонентлы аваз ияртемнәре: *ха-ха-ха, хи-хи-хи, ка-ка-ка, кыт-кыт-кыт һ.б.*

**VII.** *Үз бакчабызда әти үстергән кишер чөгендер кәбестә кебек яшелчәләрдән әни телеңне йотарлык тәмле бөккәннәр бүтән төрле ризыклар пешерә ә без аларны бик рәхәтләнеп мактый-мактый ашый идек.* (Г.Бәширов) **җөмләсендә 1) тыныш билгеләрен куегыз һәм аңлатыгыз; 2) *тәмле* сүзенә фонетик анализ ясагыз; 3) *яшелчәләрдән* сүзен сүз төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерегез**./ В предложении 1) расставьте знаки препинания и объясните их; 2) сделайте фонетический анализ слова ***тәмле; 3) с***делайте разбор слова я***шелчәләрдән.*** *(20 баллов. За знаки препинания – 5 баллов; за фонетический анализ – 10 баллов; за расбор слова – 5 баллов.).*

1. *Үз бакчабызда әти үстергән кишер**,** чөгендер, кәбестә кебек яшелчәләрдән әни телеңне йотарлык тәмле бөккәннәр**,** бүтән төрле ризыклар пешерә**,** ә без аларны бик рәхәтләнеп, мактый-мактый ашый идек.* (Г.Бәширов)

Тиңдәш кисәкләр арасына өтер куела. Каршы куючы теркәгеч ярдәмендә бәйләнгән тезүле бәйләнештәге компонентлар арасына шулай ук өтер куела.

2. ***Тәмле*** [тәм-нэ] 2 иҗек, беренчесе – ябык, икенчесе - ачык, басым икенче иҗеккә төшә.

***5 аваз*** [т], [ә], [м], [н], [э]; ***5 хәреф:*** т, ә, м, л, е

Сузыклар: [ә], [э]

[ә] – алгы рәт, иренләшмәгән, түбән күтәрелеш, озын сузык.

[э] – алгы рәт, иренләшмәгән, урта күтәрелеш, кыска сузык (басым астында озын әйтелә)

Сүздә рәт гармониясе саклана.

Тартыклар: [т], [м], [н]

[т] – саңгырау тартык (яңг пары – д), тел алды тартыгы.

[м] – сонор, ирен-ирен тартыгы

[н] – сонор, тел алды тартыгы

Сүзнең әйтелеше белән язылышы туры килми, сүздә ассимиляция күзәтелә.

3. ***Яшелчәләрдән*** сүзен сүз төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерегез. / Сделайте разбор слова. (5 баллов)

Яшел-чә-ләр-дән

**VIII. «Татар-информ» агентлыгына биргән бер интервьюсында танылган язучы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батулла: «Татар милләтен**

**йолалар гына саклап калачак» дигән иде. Сез ничек уйлыйсыз? Бу фикергә үз мөнәсәбәтегезне 80 сүздән ким булмаган язмада белдерегез. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** / В одном из интервью, данном агентству «**Татар-информ», известный татарский писатель, драматург, общественный деятель Рабит Батулла сказал** «Татарскую нацию сохранит только обычаи (традиции)». Как Вы думаете? Напишите сочинение-рассуждение (не менее 80 слов), выражая ваше отношение к этому. Приведите не менее 2 довода-примера. *(20 баллов)*

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге гомуми. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил дә юк | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган, | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | **яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |